**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

г.Казань

31.05.2016 № 01-02/225

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе утырышын уздырыр өчен нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм хәбәрнамәләре керү Тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге Федераль дәүләт хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссияләре турындагы 821 номерлы Указы белән расланган Нигезләмәсенең 16 пунктының “б” пунктчасы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссияләре турындагы 569-ПУ номерлы Указы белән расланган Нигезләмәсенең 15 пунктының “б” пунктчасы нигезендә **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе утырышын уздырыр өчен нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм хәбәрнамәләре керүнең әлеге Тәртибен расларга.

2. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгына (Латыева Т.Ю.) тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы аппаратындагы һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларындагы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук алар белән хезмәт килешүләре төзегән чакта гражданнарны әлеге боерык белән таныштыруны;

әлеге Тәртипне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының “Коррупциягә каршы сәясәт” мәгълүмат стендына урнаштыруны.

3. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында мәгълүматны мәгълүмат стендларында урнаштыру өчен җаваплы затларга Тәртипне суд участоклары стендларында урнаштырырга.

4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (Сафин А.Г.) әлеге боерыкны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтының “Коррупциягә каршы тору” бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы
юстиция министрының
2016 елның 31 маендагы
01-02/225 боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе утырышын уздырыр өчен нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм хәбәрнамәләре керү тәртибе

1.Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе утырышын уздырыр өчен нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм хәбәрнамәләре керү тәртибе (алга таба - Тәртип) кадрлар бүлегенә һәм дәүләт хезмәтенә керү процедурасын регламентлый:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтен биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре тапшырырга тиешле керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне бирергә тиешле министр боерыгы белән расланган исемлеккә кертелә торган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамәләр нигезендә эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) ризалык бирүе турындагы мөрәҗәгате, әгәр дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел узганчы аның вазыйфаи (хезмәттәге) бурычлары шушы оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләренә кергән булса;

дәүләт граждан хезмәткәренең иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне бирү объектив сәбәпләр аркасында мөмкин булмау турындагы гаризасының;

дәүләт граждан хезмәткәренең территориясендәге банкта счетлары (кертемнәре) булган, акчалары һәм кыйммәтле нәрсәләре саклана торган һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларына ия булган дәүләтнең законнары нигезендә компетентлы органнар тарафыннан кулга алынган яисә аның ихтыярына яисә

хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган баларының ихтыярына бәйле булмаган бүтән сәбәпләр буенча счетлардан (кертемнәрдән), акчаларыннан һәм кыйммәтле нәрсәләреннән һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларыннан файдалану һәм аларга ия булу тыелуга бәйле рәвештә “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау хакында гаризасының.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы туу турында хәбәрнамәсе керү һәм каралу тәртибе Татарстан Республикасы юстиция министрының 2016 елның 13 февралендәге 01-02/50 номерлы боерыгы белән көйләнә.

2. Гражданинның мөрәҗәгате һәм дәүләт граждан хезмәткәренең гаризалары әлеге Тәртипнең 1, 2 һәм 3 нче Кушымталары нигезендә язма формада төзелә һәм оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге аша министрга юллана.

3. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) өч эш көне дәвамында мөрәҗәгатьне (гаризаны), алга таба карау өчен, коррупция һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) юллый.

4. Мөрәҗәгатьне (гаризаны) беренче карау барышында җаваплы зат мөрәҗәгатьне (гаризаны) юллаучы гражданиннан яки граждан хезмәткәреннән анда әйтелгәннәр буенча аңлатмалар бирүен сорый.

5. Мөрәҗәгатьне (гаризаны) беренче карау, шулай ук аңлатмаларны өйрәнү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат язма формада нигезле бәяләмә әзерли. Мөрәҗәгать (гариза), гражданин яки граждан хезмәткәре тарафыннан мөрәҗәгатькә (гаризага) теркәлгән материаллар (алар булган очракта), аларны беренче карау барышында алынган аңлатмалар, шулай ук нигезле бәяләмә мөрәҗәгать (гариза) кергәннән соңгы җиде эш көне дәвамында җаваплы зат тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Комиссия мөрәҗәгатьне (гаризаны), аңлатмаларны һәм башка материалларны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр

конфликтын көйләү Комиссиясе турындагы Нигезләмә нигезендә карый.

---

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе утырышын уздырыр өчен нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм хәбәрнамәләре керү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
юстиция министры
______________________________________
_________________________________
(вазыйфаның исеме)
______________________________________
______________________________________
______________________________________
(Ф.И.Ә.и., телефон номеры)

Иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне бирү объектив сәбәпләр аркасында мөмкин булмау турында
гариза

________________________________________________________________________
(Комиссия әлеге белешмәләр бирелмәү сәбәпләрен
________________________________________________________________________
объектив һәм ихтирамга лаек дигән нәтиҗә ясый алсын
________________________________________________________________________
өчен барлык сәбәпләр күрсәтелә һәм килеп туган хәлләр аңлатыла)
бәйле рәвештә, үземнең
________________________________________________________________________
(хатынның, ирнең һәм (яки) балигъ булмаган балаларның Ф.И.Ә.и., туган елы)
________________________________________________________________________
керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне бирү мөмкинлегем булмавы турында белдерәм.
Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны (алар булган очракта) терким:

___

(өстәмә материаллар күрсәтелә)

___

Әлеге белешмәләрне бирү буенча граждан хезмәткәре тарафыннан күрелгән чаралар:

___

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясенең әлеге гариза карала торган утырышында шәхсән катнашырга уйлыйм/уйламыйм (кирәклесенең астына сызарга).

| ___ | ___ | ___ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаның тулысынча язылышы) |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе утырышын уздырыр өчен нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы юстиция министры

___

___
(вазыйфаның исеме)

___
___
___
(Ф.И.Ә.и., телефон номеры)

## Гариза

___
(Комиссия федераль закон таләпләренең үтәлмәве сәбәпләрен объектив һәм ихтирамга лаек
___
дип нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр күрсәтелә
___
һәм килеп туган хәлләр аңлатыла)

сәбәпле, дәүләт граждан хезмәткәренең территориясендәге банкта счетлары (кертемнәре) булган, акчалары һәм кыйммәтле нәрсәләре саклана торган һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларына ия булган дәүләтнең законнары нигезендә компетентлы органнар тарафыннан кулга алынган яисә аның ихтыярына яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган баларының ихтыярына бәйле булмаган бүтән сәбәпләр буенча счетлардан (кертемнәрдән), акчаларыннан һәм кыйммәтле нәрсәләреннән һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларыннан файдалану һәм

аларга ия булу тыелуга бәйле рәвештә “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегем булмау хакында белдерәм.

Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны (алар булган очракта) терким:

___________________________________________________________________________

(өстәмә материаллар күрсәтелә)

___________________________________________________________________

Күрелгән чаралар:

___________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясенең әлеге гариза карала торган утырышында шәхсән катнашырга уйлыйм/уйламыйм (кирәклесенең астына сызарга).

__________ __________ ___________________________

(дата) (имза) (имзаның тулысынча язылышы)

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе утырышын уздырыр өчен нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибенә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы юстиция министры

____________________________________

________________________________

____________________________________

____________________________________

____________________________________

(Ф.И.Ә.и., телефон номеры)

Коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамәләр нигезендә эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) ризалык бирү турындагы

мөрәҗәгать

Мин,_________________________________________________________________,

(Ф.И.Ә.и.)

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында __________ нан __________ га кадәр дәүләт граждан хезмәтенең _________________

(вазыйфаның исеме)

башкардым һәм 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

______________________________________________________________

(гражданин урнашырга ниятләгән вазыйфаның аталышы)

яки

____________________________________________________________________

(коммерциячел булган яки коммерциячел булмаган оешманың аталышы)

граждан-хокукый шартнамә нигезендә эшләр бшкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә)

______________________________________________________________

(гражданин башкарачак эш төрләре, хезмәт күрсәтүнең исеме)

рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Минем вазыйфаи бурычларыма керәчәк (мин башкара торган эш үз эченә алачак):

______________________________________________________________

(вазыйфаи бурычларның, граждан-хокукый шартнамә төзелгән очракта башкарылачак эшләрнең төре, кыскача сурәтләнеше)

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясенең әлеге мөрәҗәгать карала торган утырышында шәхсән катнашырга уйлыйм/уйламыйм (кирәклесенең астына сызарга).

| __________ | __________ | __________________________ |
| --- | --- | --- |
| (дата) | (имза) | (имзаның тулысынча язылышы) |